МНОГОПРОФИЛЬНАЯ
ШКОЛА №181

*Казан шәһәре Совет районы “Күп профильле 181 нче мәктәп”*



# «Күкнең җиденче катында»

№1 сентябрь 2019нчы ел

***Сез кулыгызга гәҗитебезнең иң беренче, иң “кайнар” сентябрь басмасын алдыгыз. Әлбәттә, ул төп бәйрәмнәребезнең берсе-Белем бәйрәменә багышланган.***

***Мәктәбебез тормышы, анда булган яңалыкларга битараф булмаганнар өчен, безнең гәҗитебез кызыклы һәм кирәкле булыр, дип ышанабыз.***

***Гәҗитебезгә язмаларыгызны бастырырга теләсәгез, безгә аларны алып килә аласыз. Без язмаларыгызны бастырып чыгарып, сезгә җиткерербез.***

***Без ай саен сезне гәҗитебезнең яңа саннары белән шатландырырга әзер!***



1нче сентябрь - Белем бәйрәме

Эх, бу календарьнең кызыл бите-Белем бәйрәме көне!

Белем бәйрәме... Бу көнне, җәйге каникулларыннан соң, укучылар мәктәпкә киләләр. Кемнәрдер, дусларын сагынып, мәктәпкә йөгерә-йөгерә килсә, кайберләре җәйге эссе көннәрне сагынып, моңсулана. Эх! Җәй бик тә, бик тә тиз узып китте шул...

Менә бәйрәмебезнең тантаналы өлеше-линейка да башланып китте. Укучылар, бер рәткә тезелеп басып, мәктәбебез директоры Динә Альберт кызы Абдуллина сәламләү сүзләрен тыңлый.

... Бу уку елында 1 нче сыйныфыбызга 280 укучы килгән. Бүген беренче сыйныфларыбыз, беренче мәртәбә мәктәп бусагасын атлап керәчәкләр, үз классларын күрәчәкләр, сыйныф җитәкчесе белән танышачаклар...

Укучыларның класс кабинетлары шундый җайлы, аларда ниндидер рәхәтлек хөкем сөрә.

Укучылар яраткан укытучыларына чәчәк бәйләмнәре бүләк итәләр.

Кояш көлеп карый, бигрәк күңелле бәйрәм, әйе бит?!

Чың итеп ала ул,

Кыңгырау – җиз батыр,

Ныграк кагылсаң,

Мәктәпне кузгалтыр.

Йә, дустым, чылтырат,

Бүгеннән – мәктәпкә,

Бүгеннән – зур юлга!

Хәерле сәгатьтә!

Уку елы башлану белән укучыларның организмнарына йөкләмәләр дә арта, өстәвенә көз фасылы да тәэсир итә.

Укучыларга белем туплап, яхшы билгеләргә генә укыр өчен, организмның нык, сәламәт булуы кирәк.

Организмыбыз дәресләр, түгәрәкләр кебек вазыйфаларны үтәү өчен тулысынча эшче көчендә булырга тиеш.

Укучыларыбыз талчыкмасын, игътибарлары азаймасын өчен, аларның сәламәтлекләре бик яхшы булырга тиеш.

**Айболит табиб**ыбыз безгә нәрсә киңәш итәр икән?

**Киңәшләр:**

1.Көне буена көч булсын, йокы таралсын өчен, иртәнге гимнастиканы ясарга;

2.Гимнастиканы яхшылап җилләтелгән бүлмәдә, көн матур булса, урамда ясау яхшы.

3.Гимнастика йөрәк-кан системасына уңай тәэсир итә, йөрәк-кан эшчәнлеген яхшырта.

4.Чыныгыгыз, спорт белән күбрәк шөгыльләнегез.

5.Күзләр өчен файдалы ризыклар белән тукланыгыз.

6. Йокыга ятарга ике сәгать кала, бар эшләрегезне дә төгәлләгез.




### **Ни өчен Белем бәйрәмен “Беренче кыңгырау” бәйрәме дип йөртәләр соң?**

Белем бәйрәме - ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Бу көнне һәр укучы, чәчәк бәйләме тотып, уку йортына ашыга. Күпләр бу бәйрәмне “Беренче кыңгырау” бәйрәме дип тә йөртәләр, чөнки нәкъ менә бу көнне мәктәп балалар бакчасыннан килгән “яңа” укучыларын каршы ала. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель тоткан укучылар беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша, беренче кыңгырау тавышын ишетә.

1 нче сентябрь рәсми рәвештә «Белем көне” дип беренче тапкыр 1984 нче елда игълан ителә. Бу көнне һәр укучы бәйрәм итә. Шулай да “Белем бәйрәме”н беренче сыйныфка баручылар аерым бер дулкынлану белән көтеп ала.

**Хөрмәтле укытучылар һәм укучылар!**

Алда - чираттагы уку елы. Әлеге уку елында без моңа кадәр алган белемнәрне ныгытырбыз, алар янына яңаларын өстәрбез. Җәен ял итеп килгән, яисә бакчаларда эшләп тагын да күбрәк көч туплаган кулларыбыз яңа һөнәрләр үзләштерергә әзер. Башларыбыз саф, күзләребез яңа көнгә елмаеп карый. Димәк, без Белем иленең ишекләрен киң итеп ачып керергә әзер. Бәйрәм белән сезне, дуслар!



## Мәктәпкә кагылышлы кагыйдәләрне искә төшерәбез.

1.Ягымлы бул, исәнләшергә онытма!
2.Аяк киемеңне алмаштырырга онытма!
3.Шәхси гигиенаны сакла!
4.Дәрескә соңга калма!
5.Дәрестә игътибарлы бул!
6. Дәрестә кул күтәреп кенә җавап бир!
7.Тәнәфестә йөгермә!



## Мәктәп кануннары

Һәрбер мәктәптә укытучылар һәм укучылар өчен эчке тәртип кануннары бар.
Мәктәбебезнең эчке тәртип кагыйдәләренә гардероб һәм киемгә кагылышлы таләпләр; дәрес, тәнәфес, өй эшләре, билгеләр, соңга калулар; дәрестә һәм тәнәфестә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре; алардан тыш, укучыларны яхшы укулары өчен мактау да керә.
Һәр дәүләтнең үз кануннары бар. Мәктәп – ул үз кануннары, үз таләпләре булган бер кечкенә генә дәүләт.
Мәктәбебезнең эчке тәртип кагыйдәләре – мәктәп эчендә үтәлергә тиешле кагыйдәләр. Бөтен кануннар да үтәлергә тиеш. Ни өчен дисезме? Мәктәбебездә тәртип булсын өчен!
Тәртип безнең тышкы кыяфәтебездән алып, эчке дөньябызга кадәр булырга тиеш.
Кануннар күп булырга мөмкин түгел, ләкин аларны үтәргә кирәк!

## Беренче сыйныф укучыларының әти-әниләренә киңәшләр:

1.Мәктәпкә иртәрәк чыгып китегез.Бала мәктәпкә ашыгып бармаска тиеш.

2.Балагызга куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерегез.

3.Игътибар таләп итүче урыннар янында тукталып, уйларга өйрәтегез.

4.Юлда барганда, бала юлны карап һәм өйрәнеп барсын өчен, сөйләшеп бармаска тырышыгыз.

5.Балагызны хәрәкәтләнүче машинаны күзәтергә өйрәтегез:
Кайсы транспорт борылырга әзерләнә;
Ни өчен тизлеген киметкән;
Әкрен баручы транспорт артыннан кызу килүчесе юкмы һ.б.

## Сез беләсезме?

**Франция**дәге мәктәпләр милли төсмере белән аерылып торалар: беренче мәктәпләр - “Әниле мәктәп”, монда 2-3 яшьлек балалар гомуми башлангыч белемне ала башлый. 5 яшьтә укый белергә тиешләр; Франциядә башлангыч белем 5 елга сузыла; аннары укучылар 4 ел буена көллияттә укыйлар; 2-3 ел лицейда белем алалар. Өченче баскычта белем алуның билгеле бер өлкәсенә укып чыгалар. Франциядә уку бик авыр, шуңа күрә лицейны 80 % укучы гына тәмамлап чыга ала.

**Вьетнам** мәктәпләре дәресне йога белән башлап җибәрә. Лотос рәвешендә башланган йога, акыл-

эшчәнлеген арттыра, дип саный алар.

**Бөекбритания** түрәләре сленг эшләүне тыялар. Укучылар: “сәлам”, “пока” дигән сүзләрне “Хәерле иртә!”, “Сау бул!” сүзләре белән алмаштырырга тиеш. Кыскартып сөйләшүләр тыела. Ни өчен болай эшлиләр соң? Укучыларның сөйләм телен матурлар, бизәр өчен, - ди Бөекбритания түрәләре.

**Мексикада** балаларны укытуның түбәндәге юлын уйлап чыгарганнар: Ерак авылларда яшәп, белем алырга уңайлыклары булмаган мексика балаларын 1-2 студент, шул авылларда яшәп, укыталар. Бу укучыларны укыткан өчен ел ахырында грант алалар. Ел саен бу программа буенча 300 меңнән артык бала белем ала.

## Укытучылар көне белән Сезне, хөрмәтле укытучылар!

Тиздән **Укытучылар көне** дә килеп җитә. Без, гәҗитебезнең хәбәрчеләре, хөрмәтле укытучыларыбызны һөнәри бәйрәмнәре белән котларга ашыгабыз.
Сабырлылыгыгыз, белем бирүегез, безгә икенче Әни булуыгыз өчен, Рәхмәт, Сезгә!
Укытучы һөнәре - иң авыр һөнәрләрнең берсе. Сез безне сабыр гына тыңлап, төпле киңәшләрегезне биреп, безнең өчен борчылучы олуг заттыр.
Безгә биргән төпле белемнәрегез югалмас, без аларны тормышыбызда кулланырга сүз бирәбез!
Сезгә саулык, иминлек, җаваплы хезмәтегездә уңышлар телибез!

МНОГОПРОФИЛЬНАЯ
ШКОЛА №181

**Редакциянең адресы:**
420101 Казан шәһәре,
Тулпар урамы, 2
Тел. 89050229576
**Тираж** – 50 экз.
**Баш мөхәррир һәм дизайнер:**
Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы
**Редколлегия әгъзалары:**
Әхмәтҗанова Рузинә, Корчагина Яна, Мельникова Аделина, Мәхмүтова Мәдинә, Хөснетдинова Камелия, Шангараева Милана, Шакирова Кира, Хәсәнова Аделя, Гиниятова Камилла, Соколова София,Сафина Камилла, Овезова Лейла, Закирова Азалия, Гиниятов Салават, Фатыхова Даяна

***

